Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
"Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Ябалак авылында гражданнар җыенының
"Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегенең
Ябалак авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм 2021 елда үзара салым кертү
турында" 2020 елның 13нче ноябрендәге 3нче номерлы карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Ябалак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш), 500 (биш йөз) сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертүгә рөхсәт итәсезме »дигән мәсьәлә буенча 2020 елның 13нче ноябрендә Ябалак авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде,һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:

- Ябалак авылының Х. Такташ урамы буенча вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар гражданнар исемлегенә 186 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 101 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенында катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 101 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Ябалак авылында халык җыены узган, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Ябалак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар , балачактан инвалидлар; коляскадагы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш),2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга һәм - түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

- Ябалак авылының Х. Такташ урамы буенча вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегенең Ябалак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә (көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, балачактан инвалидлар; коляскалы инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, күп балалы гаиләләрдән тыш) 2021 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

• Ябалак авылының Х. Такташ урамы буенча вак таш җәю һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту

4.Гражданнар җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

**Шәмбалыкчы авыл җирлеге Башлыгы:** **Ф. Ф. Миңнуллин**